## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

### КАРАР

«22» 05 2024 ел Яр Чаллы №2279

«2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 1 февралендәге 312 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 22 апрелендәге 862-р номерлы күрсәтмәсе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү нигезендә, күрсәтелгән учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре алуга бәйле рәвештә физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль биремне үтәвен финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә һәм планлаштырылган район чаралары саны кимүгә бәйле рәвештә

### КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 1 февралендәге 312 номерлы карары белән расланган (2024 елның 22 мартындагы 761 номерлы үзгәрешләр белән) «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2024 елга Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесен финанслау күләмен Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү хисабына 287688,96 сум күләмендә арттырырга.
- 2024 елга «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен финанслау күләмен 200000,00 сум күләмендә киметергә (планлаштырылган район чаралары саны кимү).

2. «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасы паспортының «Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләмнәре» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләмнәре | 2024-2026 елларда ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 7 072 968,96 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2024 елда – 2 560 9680,96 сум;<br>2025 елда – 2 256 000 сум;<br>2026 елда – 2 256 000 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар» кушымтасында «Яшәү урыннары буенча барлык яшьтәге халык катнашында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чаралар үткәрү» 17 пунктында 2024 елга «Тукай муниципаль районының яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен финанслау күләмен 200000,00 сум күләмендә киметергә, «Район территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыруга бәйле чаралар, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру (аутсорсинг)» 20 пунктында 2024 елга Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенә 287688,96 сум финанс средстволарын өстәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин